| | |
|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |

№ 73/о

П Р И К А З　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Б О Е Р Ы К

«20» 04 2017

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының "Проект документациясенә һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2016 елның 11 октябрендәге 167/о номерлы боерыгы белән расланган Проект документациясенә һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында" 2007 елның 5 мартыннан 145 номерлы карары белән расланган Проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын оештыру һәм үткәрү турында нигезләмә нигезендә

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 11 октябрендәге 167/о номерлы боерыгы белән расланган Проект документациясенә һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4 пунктында:

"Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге" графасының 4 пунктчасындагы беренче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Мөрәҗәгать итүче инициативасы белән дәүләт экспертизасын үткәрү вакытлары шартнамәдә билгеләнгән тәртиптә 30 көннән артмаган чорга

озынайтылырга мөмкин.";

"Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив акт" графасында "28" саннарыннан соң "29.1" саннарын өстәргә;

"Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге" графасының 2.5 пунктында:

өченче, дүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Проект документациясе һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре тискәре дәүләт экспертизасы бәяләмәсендә күрсәтелгән җитешсезлекләрне юкка чыгарганнан соң яисә уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алган проект документларына капиталь төзелеш объектының конструктив һәм куркынычсызлык буенча башка сыйфатламаларына тия торган техник чишелешләрне үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертелгәндә дәүләт экспертизасына яңадан (икенче һәм аннан соңгы мәртәбә) җибәрелә.

Уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алган проект документациясе, аңа капиталь төзелеш объектының конструктив һәм куркынычсызлык буенча башка сыйфатламаларына тия торган техник чишелешләрне үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертелгән очракта, төзүченең яисә техник заказчының инициативасы буенча дәүләт экспертизасына яңадан (икенче һәм аннан соңгы мәртәбә) җибәрелергә мөмкин.";

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"эшләр башкаручыны проект документациясен әзерләү буенча тиешле эшләр төренә һәм (яки) инженерлык эзләнүләренә кертү турында үзеннән-үзе җайга салынулы оешма тарафыннан бирелгән, проект документациясен һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләрен төзүчегә (техник заказчыга) тапшыру көненә гамәлдә булган таныклыклар, әгәр дә Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый эшләргә рөхсәт алу мәҗбүри булса, һәм проект документациясен һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләрен төзүчегә (техник заказчыга) тапшыруны раслый торган документ (яисә, документларны кәгазьдә тапшырган очракта аларның күчермәләре, әгәр дә Россия Федерациясе законнары нигезендә кәгазьдә тапшыру рөхсәт ителсә);";

"Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге" графасының 2.10 пунктында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: "Проект документациясен модификацияләү турында бәяләмә биргән өчен аңа карата модификацияләү үткәрелгән проект документациясенә дәүләт экспертизасын үткәргән өчен проект документациясен модификацияләү турында бәяләмә бирү буенча хезмәтләр күрсәтү турында шартнамә төзү датасына исәпләнгән түләү зурлыгының 10 проценты күләмендә түләү алына.";

"Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге" графасының 2.15 пунктындагы алтынчы абзацына түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә: "инвалидларга алар тарафыннан башка затлар белән тигез шартларда хезмәтләр алырга комачау итә торган, бинаның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган бүтән каршылыкларны җиңәргә ярдәм итү";

Регламентның "3.12", "3.13" пунктларындагы нумерацияне "3.1.12", "3.1.13"кә алмаштырырга;

5.1 пунктның икенче абзацында түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә: "яисә монополиягә каршы органга.";

Регламентка 2 нче кушымтаның 3.1 пунктында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Заказчының язмача мөрәҗәгате нигезендә дәүләт экспертизасын үткәрү вакытлары иң күбе 30 көнгә озынайтылырга мөмкин.”;

Регламентка 3 нче кушымтада:

1 пунктта:

“а” пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“дәүләт экспертизасын үткәрү өчен тапшырылган проект документациясен әзерләгәндә яңадан файдаланылучы проект документациясеннән файдалану турында (файдаланмау сәбәпләре турында) белешмәләр, әгәр дә Россия Федерациясе законнарында яңадан файдаланылучы проект документациясеннән зарури файдаланып проект документациясен әзерләү турында таләп куелган булса;”;

“к” пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“к) эшләр башкаручыны проект документациясен әзерләү буенча тиешле эшләр төренә һәм (яки) инженерлык эзләнүләренә кертү турында үзеннән-үзе җайга салынулы оешма тарафыннан бирелгән, проект документациясен һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләрен төзүчегә (техник заказчыга) тапшыру көненә гамәлдә булган таныклыклар, әгәр дә Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый эшләргә рөхсәт алу мәҗбүри булса, һәм проект документациясен һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләрен төзүчегә (техник заказчыга) тапшыруны раслый торган документ (яисә, документларны кәгазьдә тапшырган очракта аларның күчермәләре, әгәр дә Россия Федерациясе законнары нигезендә кәгазьдә тапшыру рөхсәт ителсә);”;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Яңадан файдаланыла торган проект документациясеннән файдаланып әзерләнгән проект документациясенә һәм мондый проект документациясен әзерләү өчен башкарылган инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә бер үк вакытта дәүләт экспертизасын үткәрү өчен Нигезләмәнең 13 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырыла, шулай ук:

а) файдаланыла торган яңадан файдаланылучы проект документациясенә карата уңай экспертиза бәяләмәсе һәм үзгәртелүләргә дучар булмаган һәм, тулысынча яңадан файдаланылучы проект документациясенә туры килә торган проект документациясенең дәүләт экспертизасына тапшырылган бүлекләрен күрсәтеп, белешмә;

б) төзүченең (техник заказчының) яңадан файдаланылучы, аңа карата махсус хокук бүтән затныкы булган проект документациясеннән файдалануга хокукын раслый торган документ (махсус хокукны читләштерү турында шартнамә, лицензия шартнамәсе, сублицензия шартнамәсе һәм шуңа охшаш);

в) проектланучы капиталь төзелеш объектының аны проектлау өчен кулланылган яңадан файдаланылучы проект документациясе иң беренче мәртәбә файдалану өчен әзерләнгәндә исәпкә алынган билгеләнешенең аналогик булуын һәм проект куәтен һәм мондый капиталь төзелеш объектын төзүне гамәлгә ашыру планлаштырыла торган территориянең табигый һәм башка төрле шартларының капиталь төзелеш объектының билгеләнешенә,

проект куәтенә һәм территория шартларына туры килүен раслый торган документ, әгәр дә Россия Федерациясе законнарында яңадан файдаланылучы проект документациясеннән зарури файдаланып, проект документациясен әзерләү турында таләп билгеләнгән булса.”;

4 пунктта түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Яңадан файдаланылучы проект документациясеннән файдаланып проект документациясен әзерләгән очракта, шулай ук Нигезләмәнең 15 пунктында күрсәтелгән документлар да тапшырыла.”;

Регламентка 4 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта булып бирелә);

Регламентка 8 нче кушымта өстәргә (кушымта булып бирелә).

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю. Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С. Миңнехановага әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынганнан соң ун эш көне дәвамында “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

**Министр** **И.Ә.Фәйзуллин**

МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

ОТДЕЛ ОРГАНИЗАЦИОННО-ПРОТОКОЛЬНОЙ РАБОТЫ, КОНТРОЛЯ И ДЕЛОПРОИЗВОДСТВА

Проект документациясенә һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 20 апрелендәге 79/о номерлы боерыгы редакциясендә)
4 нче кушымта

Оешманың рәсми бланкында
(ирекле рәвештә тутырыла)

“Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасы дәүләт экспертизасы һәм бәя хасил итү идарәсе” дәүләт автоном учреждениесе башлыгына
___________________________

____елның__________№ _____

Хөрмәтле_________________________________!

Объектның проект документациясенә дәүләт экспертизасын үткәрүне сорыйм (проектлау биреме һәм проект документациясе нигезендә объектның аталышы).

| Белешмәләр исемлеге | Белешмәләр |
|---|---|
| 1. Капиталь төзелеш объекты турында идентификация белешмәләре, аңа карата дәүләт экспертизасына тапшырылган проект документациясе һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре. | Төзелеше (үзгәртеп корылышы, капиталь ремонты) күзалланган төзелеш объектының (объектларының) аталышы_____________________________ ____________________________________ ____________________________________ ____________________________________ ____________________________________; Капиталь төзелеш объектының (объектларының) почта (төзелеш) адресы: |

| | |
|---|---|
| | ______________________________________<br>______________________________________<br>______________________________________<br>______________________________________;<br>Капиталь төзелеш объектының (объектларының) төп техник-икътисадый сыйфатламалары (мәйданы, күләме, озынлыгы, катлар саны, җитештерү куәте һәм башкалар):<br>______________________________________<br>______________________________________ |
| 2. Эшләрне башкаручылар – проект документациясен әзерләүне гамәлгә ашырган һәм (яки) инженерлык эзләнүләрен башкарган затлар турында идентификация белешмәләре | Шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме, шәхесне таныклый торган документларның реквизитлары, юридик затның тулысынча аталышы:<br>______________________________________<br>______________________________________;<br>Адресы (юридик):<br>______________________________________<br>______________________________________;<br>Адресы (фактик):<br>______________________________________<br>______________________________________;<br>Җитәкченең ФИА (ШЭ өчен паспорт белешмәләре):______________________<br>______________________________________<br>______________________________________;<br>Телефоны:____________________________<br>______________________________________;<br>Шәхси эшкуарның яшәү урыны буенча почта адресы, телефоны:<br>______________________________________<br>______________________________________<br>______________________________________<br>______________________________________<br>(шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме, шәхесне таныклый торган документларның реквизитлары, яшәгән урыны буенча почта адресы, юридик зат урнашкан урын) |
| 3. Мөрәҗәгать итүче (төзүче, техник заказчы) турында идентификация белешмәләре | Оешманың тулысынча аталышы (шәхси эшкуарның ФИА, физик затның шәхесен таныклаучы документларның реквизитлары):<br>______________________________________<br>______________________________________;<br>Адресы (юридик):<br>______________________________________<br>______________________________________;<br>Адресы (фактик): |

| | |
|---|---|
| | ____________________________________<br>____________________________________;<br>Җитәкченең ФИА:____________________<br>____________________________________<br>____________________________________;<br>Телефоны:__________________________<br>____________________________________ |
| 4. Мөрәҗәгать итүче турында идентификация белешмәләре (дәүләт экспертизасын үткәрүгә шартнамә төзү өчен) | Оешманың тулысынча аталышы (шәхси эшкуарның ФИА, физик затның шәхесен таныклаучы документларның реквизитлары):<br>____________________________________;<br>____________________________________;<br>Адресы (юридик):<br>____________________________________<br>____________________________________;<br>Адресы (фактик):<br>____________________________________<br>____________________________________;<br>Җитәкченең ФИА:____________________<br>____________________________________<br>____________________________________;<br>ИНН____________________________;<br>КПП____________________________;<br>И-х/сч__________________________;<br>____________________________________<br>____________________________________<br>(банк аталышын күрсәтергә)<br>БИК____________________________;<br>к/сч____________________________;<br>Телефоны:______________________ |
| 5. Дәүләт экспертизасын үткәрү өчен тапшырылган проект документациясен әзерләгәндә яңадан файдаланылучы проект документациясеннән файдалану турында (файдаланмау сәбәпләре турында) белешмәләр (әгәр дә Россия Федерациясе законнарында яңадан файдаланылучы проект документациясеннән зарури файдаланып проект документациясен әзерләү турында таләп куелган булса) | |

**Төп белешмәләрнең исемлеге:**

Мөрәҗәгать итүченең (заказчының) җаваплы вәкиле:

(ФИА, вазыйфасы, телефоны.)

Җитәкченең – мөрәҗәгать итүченең вазыйфасы имзасы, Ф.И.А.

м.у.

Проект документациясенә һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 20 апрелендәге 79/о номерлы боерыгы редакциясендә)
8 нче кушымта

“Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасы дәүләт экспертизасы һәм бәя хасил итү идарәсе” дәүләт автоном учреждениесе башлыгына
______________________________

____елның__________№ _____

Техник хатаны (хәреф, язу хатасын, грамматик яисә арифметика хатасын) төзәтү турында гариза

______________________________________________________________________
(дәүләт хезмәтенең аталышы)
дәүләт хезмәтен күрсәткәндә җибәрелгән техник хата (хәреф, язу хатасы, грамматик яисә арифметика хатасы) турында хәбәр итәм.

Язылган:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

Дөрес белешмәләр:
______________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны (хәреф, язу хатасын, грамматик яисә арифметика хатасын) төзәтүне һәм дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертелүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1. 4 (дүрт) нөсхәдә уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсе яисә 1 (бер) нөсхәдә тискәре дәүләт экспертизасы бәяләмәсе;
2. ____________________________________________________________________

2. ______________________________________________________________________

______________________________________________________________________;
3.____________________________________________________________________

Техник хатаны (хәреф, язу хатасын, грамматик яисә арифметика хатасын) төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта мондый карарны

_____________________________________________________электрон почта адресына электрон документ рәвешендә җибәрү юлы белән;

_____________________________________________________ адресы буенча таныкланган күчермә рәвешендә кәгазьдә почта аша җибәрүне сорыйм.

Хәзергесе белән раслыйм: гаризага кертелгән, минем шәхесемә һәм минем вәкаләтле затыма кагыла торган, шулай ук түбәндә минем тарафтан кертелгән белешмәләр дөрес.

Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә һәм гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм алардагы белешмәләр дөрес.

______________ ______________(____________________________)
(дата) (имза) (Ф.И.А.)